| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>Исполнительный комитет<br>Старошешминского сельского поселения<br>Нижнекамского муниципального района | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>Түбән Кама муниципаль районынын<br>Иске Чишмэ жирлеге<br>Башкарма комитеты |
|---|---|
| 423563, Нижнекамский район,<br>с. Старошешминск, ул.Ленина, 4 | 423563, Түбэн Кама районы,<br>Иске Чишмэ авылы, Ленин урамы, 4 |

тел./факс (8555) 33-46-48, электронный адрес: Starosheshminskoe.Sp@tatar.ru, сайт: www. starosheshminskoe-sp.ru


ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

17.11.2023ел № 33

Россия Федерациясе Гражданлык кодексының 287.7 статьясында каралган вәкаләтләрне Иске Чишмэ авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Гражданлык кодексының 287.7 статьясына, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «Иске Чишмэ авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 47 статьясы, Иске Чишмэ авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Россия Федерациясе Гражданлык кодексының 287.7 статьясында каралган вәкаләтләрне Афанас авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан гамәлгә ашыруның кушымта итеп бирелгән тәртибен расларга.
2. Әлеге карарны законнарда билгеләнгән тәртиптә игълан итәргә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Е.Ю. Ермаков

Татарстан Республикасы Иске Чишмэ авыл җирлеге комитетының
2023 елның «17» ноябре
35 номерлы карары белән расланган кушымта

## Россия Федерациясе Гражданлык кодексының 287.7 статьясында каралган вәкаләтләрне Иске Чишмэ авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан гамәлгә ашыру тәртибе

### 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Тәртип Россия Федерациясе Гражданлык кодексының 287.7 статьясы нигезендә, әгәр урын милекчесе аны тиеш булган максатларда кулланмаса, күршеләрнең хокукларын һәм мәнфәгатьләрен системалы рәвештә бозса, яки урынны хуҗалыкчыл булмаган хәлдә тотып, аны җимерүгә юл куйган очракта, Иске Чишмэ авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан хокук бозуларны бетерү зарурлыгы турында кисәтү җибәрү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өлешендә эшләнгән.

1.2. Әлеге тәртип максатлары өчен, түбәндәге төшенчәләр кулланыла:

а) вәкаләтле орган - Афанас авыл җирлеге башкарма комитеты;

б) хокук бозулар - урынны тиеш булган максатларда куллану, күршеләрнең хокукларын һәм мәнфәгатьләрен системалы рәвештә бозу, яки урынны хуҗалыкчыл булмаган хәлдә тотып, аны җимерүгә юл кую;

в) хокук бозуларны бетерү турында кисәтү - вәкаләтле орган тарафыннан әлеге Тәртипкә 1, 2 нче кушымталар нигезендә форма буенча әзерләнгән, хокук бозуларга юл куйган урын милекчесенә адресланган һәм хокук бозуларны бетерү кирәклеге яки күршеләрнең хокукларын һәм мәнфәгатьләрен кабат бозуга юл куймау турындагы таләпне үз эченә алган язма акт.

1.3. Әлеге Тәртиптә кулланыла торган башка төшенчәләр Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларындагы кебек үк мәгънәләрдә кулланыла.

### 2. Хокук бозуларны бетерү турында кисәтү чыгару тәртибе

2.1. Вәкаләтле орган тарафыннан урын хуҗасына хокук бозуларны бетерү турында кисәтү әзерләү һәм җибәрү өчен нигез булып, вәкаләтле органга кергән документлар һәм хокук бозулар фактын раслаучы материаллар тора, шул исәптән:

хокук бозу фактларын ачыклау компетенциясенә ия булган органнардан яки вазыйфаи затлардан килгән документлар һәм материаллар;

хокук бозу фактларын ачыклау компетенциясенә ия булган органнар яки вазыйфаи затлар тарафыннан әзерләнгән документлар һәм материаллар белән физик яки юридик затларның мөрәҗәгатьләре.

2.2. Хокук бозулар турында мәгълүмат булган физик яки юридик затларның мөрәҗәгатьләре вәкаләтле орган тарафыннан «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, әлеге Тәртиптә каралган үзенчәлекләрне исәпкә алып карала.

Әгәр мөрәҗәгатьләрдә күрсәтелгән хокук бозулар турындагы мәгълүмат хокук бозу фактларын билгеләү компетенциясенә ия булган органнар яки вазыйфаи затларның аңа кушып бирелгән документлар һәм материаллары белән расланмаса, вәкаләтле орган «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда күрсәтелгән мөрәҗәгатьләрне, гамәлдәге законнарда билгеләнгән компетенцияләр кысаларында тиешле чаралар күрү өчен, тиешле вазыйфаи затка, дәүләт хакимияте органына, җирле үзидарә органына җибәрә.

Мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән хокук бозулар фактын раслау максатыннан, вәкаләтле орган компетенция буенча мөрәҗәгать җибәрү белән бер үк вакытта мондый мөрәҗәгатьне карау нәтиҗәләре турында документлар һәм материаллар сората.

Хокук бозулар фактын раслаучы документлар һәм материаллар булган мөрәҗәгатьне карау нәтиҗәләре кергәч, вәкаләтле орган 7 көн эчендә әлеге Тәртип буенча хокук бозуларны бетерү турында кисәтүне милекчегә тапшыра яки заказ хаты белән җибәрә.

2.3. Кисәтүдә күрсәтелгән срок тәмамлангач, әгәр милекче күршеләрнең хокукларын һәм мәнфәгатьләрен бозуны дәвам итсә яки урынны тиешле максатларда файдаланмаса яки җитди сәбәпләрсез кирәкле ремонт ясамаса, вәкаләтле орган 10 көн эчендә сатудан кергән акчаны, суд карарын үтәүгә киткән чыгымнарны тотып калып, милекчегә түләп, мондый урынны гавами торгларда сату турында дәгъва гаризасы белән судка мөрәҗәгать итә.

2.4. Әлеге Тәртиптә каралган кагыйдәләр Россия Федерациясе Торак кодексында каралган үзенчәлекләре булган хуҗалыкчыл булмаган хәлдә карап тотылган торак биналарга, шулай ук машина-урыннарга кулланыла, әгәр законда башкасы каралмаган булса һәм хокук мөнәсәбәтләренең асылыннан килеп чыкмаса.

Россия Федерациясе Гражданлык кодексының 287.7 статьясында каралган вәкаләтләрне Иске Чишмэ авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан гамәлгә ашыру тәртибенә
1 нче кушымта

Хокук бозуларны бетерү турында кисәтү

________________________ «___»_______________ 20__ ел

Иске Чишмэ авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан билгеләнгән: __________________________________________________________________________ адресы буенча
__________________________________________________________________________ нигезендә
(хокукны билгеләүче документның төре һәм реквизитлары)
урынның (торак бинаның, машина-урыннын) милекчесе булып
__________________________________________________________________________________ тора.
(Ф.И.А. ис., милекченең исеме)
Шул ук вакытта ________________________________________________________________
(Ф.И.А. ис., милекченең исеме)
урынны (торак урын, машина-урын) билгеләнеше буенча кулланмый/урынны (торак бина, машина-урын) хуҗалыкчыл булмаган хәлдә карап тотып, аны җимерүгә юл куя (сайларга кирәк), атап әйткәндә
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________________.
(хокук бозуларның эчтәлеге)
бу түбәндәгеләр белән раслана
_________________________________________________________________________.
Россия Федерациясе Гражданлык кодексының 287.7 статьясына таянып, Иске Чишмэ авыл җирлеге башкарма комитеты Сезгә әлеге кисәтүне алган көннән башлап __________ көн эчендә хокук бозуларны бетерүне йөкли, ягъни:
______________________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________________.
(хокук бозуларны бетерү буенча чаралар исемлеге күрсәтелә)
Әлеге кисәтүне үтәмәгән очракта, Иске Чишмэ авыл җирлеге башкарма комитеты сатудан кергән акчаны, суд карарын үтәүгә киткән чыгымнарны тотып калып, милекчегә түләп, мондый урынны (торак урын, машина-урын) гавами торгларда сату турында дәгъва гаризасы белән судка мөрәҗәгать итү буенча чаралар күрәчәк.

Башкарма комитет җитәкчесе
(яисә аның вәкаләтле заты) ФИА ис.

Кисәтүне бирде ___________________________________________________________________
(Ф.И.А.ис., вазыйфасы, кисәтүне биргән затның имзасы)
Кисәтүне алды ____________________________________________________________________
(Ф.И.А.ис., вазыйфасы, кисәтүне алган затның имзасы, яисә алудан баш тарту турында билге)
Кисәтү почта элемтәсе (заказ хаты) белән җибәрелде
______________________________________________________________________________________.
(дата, кисәтү җибәргән затның имзасы)

Россия Федерациясе Гражданлык
кодексының 287.7 статьясында
каралган вәкаләтләрне Иске Чишмэ авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан гамәлгә ашыру тәртибенә
2 нче кушымта

Күршеләрнең хокукларын һәм мәнфәгатьләрен бозуны бетерү кирәклеге турында
кисәтү

________________________ «___»_______________ 20__ ел

Иске Чишмэ авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан билгеләнгән:
_______________________________________________________________________ адресы буенча
_______________________________________________________________________ нигезендә
(хокукны билгеләүче документның төре һәм реквизитлары)
урынның (торак бинаның, машина-урынның) милекчесе булып
________________________________________________________________________________ тора.
(Ф.И.А. ис., милекченең исеме)
Шул ук вакытта _________________________________________________________________
(Ф.И.А. ис., милекченең исеме)
күршеләрнең хокукларын һәм мәнфәгатьләрен системалы рәвештә бозуга юл куйган, атап әйткәндә
_______________________________________________________________________________
_______________________________________________________________________________,
(хокук бозуларның эчтәлеге)
бу түбәндәгеләр белән раслана
_______________________________________________________________________________.

Россия Федерациясе Гражданлык кодексының 287.7 статьясына таянып, Иске Чишмэ авыл җирлеге башкарма комитеты Сезне алга таба күршеләрнең хокукларын һәм мәнфәгатьләрен бозу ярамаганлыгы турында әлеге кисәтә.

Күршеләрнең хокуклары һәм мәнфәгатьләре бозылу факты кабат ачыкланган очракта, Иске Чишмэ авыл җирлеге башкарма комитеты сатудан кергән акчаны, суд карарын үтәүгә киткән чыгымнарны тотып калып, милекчегә түләп, мондый урынны (торак урын, машина-урын) гавами торгларда сату турында дәгъва гаризасы белән судка мөрәҗәгать итү буенча чаралар күрәчәк.

Башкарма комитет җитәкчесе
(яисә аның вәкаләтле заты) ФИА ис.

Кисәтүне бирде _________________________________________________________________
(Ф.И.А.ис., вазыйфасы, кисәтүне биргән затның имзасы)
Кисәтүне алды __________________________________________________________________
(Ф.И.А.ис., вазыйфасы, кисәтүне алган затның имзасы, яисә алудан баш тарту турында билге)
Кисәтү почта элемтәсе (заказ хаты) белән җибәрелде
_______________________________________________________________________________.
(дата, кисәтү җибәргән затның имзасы)